МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.05.2021 г.Казань № 306

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 4 июнендә 7707 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган мөһим бәяләү критерияләрен раслау турында» 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган мөһим бәяләү критерияләрен раслау турында» 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 13 ноябрендәге 995 номерлы, 2019 елның 23 декабрендәге 1125 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019-2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган таләпләрне һәм аларның нигезләрен раслау турында»;

преамбулада:

«2019-2022 елларга» сүзләрен «2019-2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, аларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, аларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

боерыкның карар өлешендә:

«Кандидатураны килештергәндә кулланыла торган бәяләү критерияләренең мөһимлеген расларга» сүзләрен «Кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган таләпләрне һәм аларның нигезләрен расларга» сүзләренә алмаштырырга;

«2019-2022 елларга» сүзләрен «2019-2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, аларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, аларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

боерыкка кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 14 маендагы 306 номерлы боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 26 апрелендәге 344 номерлы карары белән расланган «2019-2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашу өчен кадидатураларны килештергәндә кулланыла торган таләпләр һәм аларның нигезләре

| «2019-2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган таләпләр | Таләпләрнең нигезе |
|---|---|
| 1. Яше | Максимум 15 |
| • 18-29 яшь | 15 |
| • 30-34 яшь | 13 |
| • 35-39 яшь | 11 |
| • 40-44 яшь | 9 |
| • 45 яшькә кадәр һәм эшкә сәләтле булган яшькә кадәр | 7 |
| • хезмәткә яраклы яшьтән өлкәнрәкләр | 5 |
| 2. Белеме | Максимум 12 |
| • Гыйльми дәрәҗәсе | 12 |
| • Мәгариф учреждениеләрендә алынган югары белеме:<br>• | |
| - Россия Федерациясендә (СССР) | 10 |
| - башка дәүләтләрдә | 8 |
| • Урта һөнәри белем, һөнәри белем | 7 |

| | |
|---|---|
| 3. Икенче югары һөнәри белеме булуы | 5 |
| 4. Эш стажы | Максимум 10 |
| • 5 елдан артык | 10 |
| • 3-5 ел | 8 |
| • 1-3 ел | 5 |
| • Бер елдан азрак | 2 |
| 5. Хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру (гариза бирү вакытына) | Максимум 15 |
| • актуаль фәнни һәм технологик эшләнмәләр өлкәсендә | 15 |
| • мәгариф, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, спорт, мәгълүмат-коммуникация технологияләре, машина төзелеше өлкәләрендә. | 12 |
| • башка өлкәләрдә | 10 |
| 6. Татарстан Республикасы икътисады үсешенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган, ел саен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган, соралучы һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлегенә туры килә торган белем (белгечлек) буенча һөнәргә (белгечлеккә) ия булу | 10 |
| 7. Кандидат белән бергә күченә торган иренең (хатынынын) һөнәри белеме булу | 4 |
| 8. Балигъ булмаганнарны да кертеп, кандидат белән бергә күченә торган балаларның булуы | 4 |
| 9. Россия Федерациясе һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында көндезге белем алу формасында белем ала торган студентлар (алынган белемен исәпкә алмыйча) | 25 |